Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

КАРАР № XLIII-4

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 15 нче ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 2 декабрендәге XXXI-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 9, 20, 21 маддәләренә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан килештерелгән 2023 елның 29 августындагы 10-53/10582 номерлы уңай бәяләмә нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 2 декабрендәге XXXI-4 номерлы карары белән расланган (район Советының 2016 елның 15 июлендәге XI-5 номерлы, 2016 елның 16 декабрендәге XIII-8 номерлы, 2018 елның 29 декабрендәге XXXVIII-3 номерлы, 2022 елның 29 октябрендәге XXVII-14 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Территориаль планлаштыру схемасына авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан түбәндәге торак пунктларның чикләре турында мәгълүмат белән тулыландыру өлешендә, аларга карата генераль план әзерләү кирәк түгеллеге турында карар кабул ителгән, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Олы Әшнәк авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Олы Әшнәк авылы;

Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Югары Тегермәнлек авылы;

Уракчы авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Мельничный Пүчинкәсе авылы;

Биектау авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Околоток-Яңасала авылы, Үрнәк поселогы;

Балтач авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Балтач авылы, Ямаш авылы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов